ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2019 с.Старое Дрожжаное № 493

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” 2018елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары гамәлен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларына таратырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын әлеге карар белән билгеләнгән

вакытка кадәр ике айдан да соңга калмыйча хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

3. Карар 2018 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма
комитет Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов